Гыйбадәт кылуга кагылышлы

# КЫРЫК ХӘДИС

Хузур – 1435/2014

www.darul-kutub.com

**ГЫЙБАДӘТ КЫЛУГА КАГЫЛЫШЛЫ КЫРЫК ХӘДИС.** – Казан: Хузур-Спокойствие, 2014. – 72 бит.

Әлеге китапчыкта хәнәфи мәзһәбе буенча намаз укуга караган төп мәсьәләләр хәдисләр ярдәмендә тикшерелә. Биредә 40 хәдис урын алган. Аларның чыганаклары күрсәтелгән, текст үзе гарәп телендә дә бирелгән. Брошюрадагы аңлатмалар барлык мөселман кардәшләребезгә дә файдалы булыр.

www.darul-kutub.com

# БЕРЕНЧЕ ХӘДИС

## Намазда тәхрим тәкбире әйтү

١ – عَنْ مَالِكِ بْنِ الحُوَيْرِثِ رَضِىَ اللهُ عَنْهُ :
أَنَّ رَسُولَ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمِ كَانَ إِذَا
كَبَّرَ رَفَعَ يَدَيْهِ حَتَّى يُحَاذِىَ بِهِمَا أُذْنَيْهِ.

Малик ибне Хуүәйристән (радыйаллаһу анһу) шулай риваять кылынган: «Рәсүлуллаһ салләллаһу гәләйһи үә сәлләмнең тәхрим тәкбире әйткәндә кулларын колакларына кадәр күтәрә иде».

Бу хәдис-шәрифне имам Мүслим һәм Нәсаи риваять кылган.

www.darul-kutub.com

## ИКЕНЧЕ ХӘДИС

### Намазда кулларны тоту рәвеше

– عَنْ وَائِلِ بْنِ حُجْرٍ رَضِىَ اللّٰهُ عَنْهُ قَالَ : «قُلْتُ : لَأَنْظُرَنَّ إِلَى صَلَاةِ رَسُولِ اللّٰهِ صَلَّى اللّٰهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ كَيْفَ يُصَلِّى ؟ فَقَامَ رَسُولُ اللّٰهِ صَلَّى اللّٰهِ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ فَاسْتَقْبَلَ الْقِبْلَةَ فَكَبَّرَ ، فَرَفَعَ يَدَيْهِ حَتَّى حَاذَتَا بِأُذُنَيْهِ ، ثُمَّ وَضَعَ يَدَهُ الْيُمْنَى عَلَى كَفِّهِ الْيُسْرَى وَالرُّسْغِ وَالسَّاعِدِ».

Үаил ибне Хужр (радыйллаһу анһу) шулай дигән:

«Рәсүлүллаһның салләллаһу гәләйһи үә сәлләмнең ничек намаз укыганын өйрәнер өчен, намаз укыганда аны күзәтеп тордым. Рәсүлүллаһ (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) аякка басты һәм кыйбла ягына юнәлеп

тәкбир әйтте. Соңыннан уң кулын, сул кулының беләзек сөяге өстенә куйды».

Бу хәдис-шәрифне имам Әхмәд, Әбү Дауд һәм Нәсаи риваять кылган.

Ибне Хәҗәр (рәхимаһуллаһ) бу хәдис-шәрифне ибн Хузәймәнең һәм башка риваять кылучыларның үзләренең риваять чылбырларына алуын хәбәр иткән.

* * *

www.darul-kutub.com

## ӨЧЕНЧЕ ХӘДИС

٣ – وَعَنْ وَائِلِ بْنِ حُجْرٍ رَضِىَ اللهُ عَنْهُ قَالَ : « رَأَيْتُ النَّبِيَّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ وَضَعَ يَمِيْنَهُ عَلَى شِمَالِهِ فِى الصَّلَاةِ تَحْتَ السُّرَّةِ».

Үаил ибне Хуҗрдан (радыйаллаһу анһу) шулай риваять кылынган:

«Мин Рәсүлүллаһ салләллаһу гәләйһи үә сәлләмнең, уң кулын сул кулының өстендә куеп, көндегенең астында тотканын күрдем».

Бу хәдис-шәрифне Ибн Әбү Шәйба (рәхимаһуллаһ) үз риваятьләре арасына керткән.

Хафиз ибн Котлыбога бу хәдис хакында: «Бу хәдиснең иснады ныктыр», – дигән.

www.darul-kutub.com

## ДҮРТЕНЧЕ ХӘДИС

### «Сүбханәкә»не уку

٤ – عَنْ عَائِشَةَ رَضِىَ اللّٰهُ عَنْهَا قَالَتْ : كَانَ
رَسُولُ اللّٰهِ صَلَّى اللّٰهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ إِذَا اسْتَفْتَحَ
الصَّلَاةَ قَالَ : «سُبْحَانَكَ اللَّهُمَّ وَبِحَمْدِكَ ،
وَتَبَارَكَ اسْمُكَ ، وَتَعَالَى جَدُّكَ وَلَا إِلَهَ غَيْرُكَ».

Хәзрәти Гайшә (радыйаллаһу анһә) шулай дигән:

Пәйгамбәр салләллаһу гәләйһи үә сәлләм намаз башлаган вакытта: *«Сүбхәәнәкә Аллаһүммә үә бихәмдикә үә тәбәракә смүкә үә тәгәәләә җәддүкә үә ләә иләәһә гайрукә»,* – дип әйтә торган иде».

Бу хәдис-шәрифне Әбү Дауд риваять иткән.

Әл-Гыйракый (рәхимаһуллаһ) исә, бу

хәдис-шәриф турында: «Иснады ышанычлы», – дигән. Аның шәкерте булган Ибне Хәҗәр (рәхимаһуллаһ): «Бу хәдиснең сәнәде аны иң кимендә хәсән-хәдисләр рәтенә кертә», – дип хәбәр иткән.

Табәрани (рәхимаһуллаһ) «Әлҗәмигуль әүсәтъ» исемле китабында бу хәдис-шәрифне башка юл белән Әнәстән (радыйаллаһу ганһу) риваять кылган.

Хафиз әл-Хәйсәми (рәхимаһуллаһ): «Хәдис-шәрифнең сәнәде ышанычлы,»– дигән.

Имам Тирмизи (рәхимаһуллаһ): «Гыйлем әһленең күбесе, Пәйгамбәр әфәндебезнең (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) шулай әйткәнен риваять кылганнар: *«Сүбхәәнәкә Аллаһүммә үә бихәмдикә үә тәбәракә смүкә үә тәгәәләә җәддүкә үә ләә иләәһә гайрукә»*.

Бу риваятьне Гомәр ибне Хаттаб һәм Габдуллаһ ибне Мәсгуд (радыйаллаһу ганһу) җиткергән.

www.darul-kutub.com

Табигыйннәрдән булган гыйлем әһелләре һәм башкалар бу хәдис белән гамәл кылган.

* * *

www.darul-kutub.com

## БИШЕНЧЕ ХӘДИС

## «Фатихә»не бисмилләсез уку

٥ – عَنْ أَنَسِ بْنِ مَالِكٍ رَضِىَ اللهِ عَنْهُ : أَنَّ النَّبِيَّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ وَأَبَا بَكْرٍ وَعُمَرَ رَضِىَ اللهُ عَنْهُمَا كَانُوا يَفْتَتِحُونَ الصَّلَاةَ بِـ «الْحَمْدِ لِلهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ».

Әнәс ибне Маликтән (радыйаллаһу ганһу) шулай риваять кылынды:

«Пәйгамбәребез (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм), Әбү Бәкер һәм Гомәр (радыйаллаһу ганһумә) ләр намазны *«Әлхәмдулилләһи Раббил гәәләмиин»* белән башлый торганнар иде».

Хәдис-шәрифне бу юл белән имам Бохари һәм Мүслим җиткергәннәр.

www.darul-kutub.com

Имам Мүслим (рәхимаһуллаһ) риваятендә шундый өстәмә ясалган: «Фатихә»нең башында да, ахырында да «Бисмилләәһи ррахмәәни ррахиим»не кабатламыйлар иде».

* * *

www.darul-kutub.com

# АЛТЫНЧЫ ХӘДИС

## Бисмилләһне эчтән уку

٦ – وَعَنِ ابْنِ عَبْدِ اللهِ بْنِ مُغَفَّلٍ قَالَ : «كَانَ عَبْدُ اللهِ بْنُ مُغَفَّلٍ إِذَا سَمِعَ أَحَدُنَا يَقْرَأُ بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ يَقُولُ : صَلَيْتُ خَلْفَ رَسُولِ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ وَخَلْفَ أَبِي بَكْرٍ وَخَلْفَ عُمَرَ رَضِيَ اللهُ عَنْهُمَا ، فَمَا سَمِعْتُ أَحَداً مِنْهُمْ قَرَأَ بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ».

Ибне Габдуллаһ ибне Мугаффәлдән (радыһаллаһу ганһу) шулай риваять кылынды:

«Габдуллаһ ибне Мугаффәл арабыздан берәрсенең «Бисмилләәһи ррахмәәни ррахиим»ны укыганыбызны ишеткән вакытта шулай дип әйтә торган иде:

«Мин пәйгамбәребезнең (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм), Әбү Бәкернең һәм Гомәрнең (радыйаллаһу ганһумә) артларында торып намаз укыдым. Аларның берсенең дә «Бисмилләәһи ррахмәәни ррахиим»не укыганнарын ишетмәдем».

Имам Нәсаи һәм Тирмизинең риваятьләрендә шулай диелгән:

«Габдуллаһ ибне Мугаффәлнең риваяте хәсәндер. Пәйгамбәребез (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) һәм гыйлем әһле булган сахәбәләрдән күбесе шул рәвештә гамәл кылганнар. Хәзрәти Әбү Бәкер, Гомәр, Госман, Гали (радыйаллаһу ганһумә), башка сахәбәләр һәм алардан соңгы табигыйннәрнең кайберләре дә бу рәвештә гамәл кылганнар».

Бу хәдис белән бәйле буларак Суфьян Сәүри, Ибн Мөбарәк, Имам Әхмәд һәм Имам Әбү Исхак (рәхимаһуллаһ) шулай дигәннәр: «Бисмилләәһи ррахмәәни ррахиим»не та-

выш белән укучыны күрмәдек, бары тик эчтән укучыларны гына күрдек.

«Тәкърибүт-Тәзһиб» китабында Ибне Габдуллаһ ибне Мугаффәлнең исеме «Йәзид» дип искә алынган.

* * *

www.darul-kutub.com

# ҖИДЕНЧЕ ХӘДИС

٧ – عَنْ جَابِرِ بْنِ عَبْدِ اللهِ رَضِىَ اللهُ عَنْهُمَا عَنِ النَّبِيِّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قَالَ : «مَنْ كَانَ لَهُ إِمَامٌ فَقِرَاءَتُهُ لَهُ قِرَاءَةٌ».

Җәбир ибне Габдуллаһ (радыйаллаһу ганһу) дан пәйгамбәребезнең (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) шулай дип боергань турында риваять кылынган:

*«Кемнәр имамга ияреп укыса, имамның кыйраәте аларның укуы урынына саналыр».*

Бу хәдис-шәрифне Имам Әхмәд риваять кылган.

Ибн Әбү Гомәр әл-Мәкдиси әл-Ханбәли (рәхимәһуллаһ): «Бу хәдиснең иснады дөрес, риваять кылучыларның барысы да ышынычлыдыр,»– дигән.

www.darulkutub.com

Габд ибн Хумәйд (рәхимәһуллаһ) шулай ук бу хәдис-шәрифне риваять кылган.

Мөхәддис әл-Бүсәйри (рәхимәһуллаһ): «Бу хәдис-шәриф Имам Мүслимнең (рәхимәһуллаһ) дөреслек шартларына туры килә,»– дигән.

Әл-Бүсәйри (рәхимәһуллаһ) искә алуынча, Әхмәд ибне Мәгъни дә (рәхимәһуллаһ) «Мүснәд» китабында бу риваятьне китергән.

Бүсәйри (рәхимәһуллаһ): «Бу хәдис ике шәехнең дә дөреслек шартларына туры килә», – дигән.

* * *

www.darulkutub.com

# Сигезенче хәдис

## Имамның артында кыйраәт кылу

٨ – وَعَنْ نَافِعٍ : أَنَّ عَبْدَ اللهِ بْنِ عُمَرَ كَانَ إِذَا سُئِلَ هَلْ يَقْرَأُ أَحَدٌ خَلْفَ الْإِمَامِ؟ قَالَ : «إِذَا صَلَّى أَحَدُكُمْ خَلْفَ الْإِمَامِ فَحَسْبُهُ قِرَاءَةُ الْإِمَامِ ، وَإِذَا صَلَّى وَحْدَهُ فَلْيَقْرَأْ». قَالَ : «وَكَانَ عَبْدُ اللهِ بْنُ عُمَرَ لَا يَقْرَأُ خَلْفَ الْإِمَامِ».

Имам Нафигъдән (рәхимәһуллаһ) шулай риваять кылынды:

«Габдуллаһ ибне Гомәрдән (радыйаллаһу ганһу) шулай диеп соралды: «Имамның артында торганда кыйраәт кылынырмы?» Ул моңа җавап итеп: «Сездән берегез имамның артында намаз кылган вакытта, имамның укуы белән җитенсен. Берүзегез генә на-

www.darulkutub.com

маз кылган вакытта исә, кыйраәт ясагыз (Коръән укыгыз),» – диде.

Имам Малик (рәхимәһуллаһ) та шулай риваять итте: «Габдуллаһ ибне Гомәр (радыйллаһу ганһу) имамның артында кыйраәт кылмаган (Коръән укымаган)».

* * *

www.darul-kutub.com

## ТУГЫЗЫНЧЫ ХӘДИС

٩ – وَعَنْ عَطَاءِ بْنِ يَسَارٍ : أَنَّهُ سَأَلَ زَيْدَ بْنَ ثَابِتٍ عَنِ الْقِرَاءَةِ مَعَ الْإِمَامِ فَقَالَ : «لَا قِرَاءَةَ مَعَ الْإِمَامِ فِي شَيْءٍ».

Гата ибне Йәсәр (рәхимәһуллаһ), Зәйд ибне Сабиттән имамга оеган вакытта кыйраәт кылынып-кылынмау турында сораган. Ул да:

«Имамга ияреп намаз кылучыга берни дә укырга кирәк түгел», – дигән.

Бу хәдис-шәрифне Имам Мүслим һәм Нәсаи китергән.

* * *

www.darulkutub.com

## УНЫНЧЫ ХӘДИС

١٠– عَنْ عُبَيْدِ اللهِ بْنِ مِقْسَمٍ : أَنَّهُ سَأَلَ عَبْدَ اللهِ بْنَ عُمَرَ وَزَيْدَ بْنَ ثَابِتٍ وَجَابِرَ بْنَ عَبْدِ اللهِ فَقَالُوا : «لَا تَقْرَأْ خَلْفَ الْإِمَامِ فِي شَيْءٍ مِنَ الصَّلَوَاتِ».

Гөбәйдуллаһ ибне Миксәмнән (радыйаллаһу ганһу) аның имам артыннан кыйраәт кылу турында Габдуллаһ ибне Гомәр, Зәйд ибне Сабит һәм Җәбир ибне Габдуллаһ (радыйаллаһу анһумә) лардән сораганлыгы риваять кылынган. Һәм алар барысы да: «Намазларда, имамның артында укыган вакытта бернәрсә дә укыма,»– дип җавап кайтарганнар.

Бу хәдис-шәрифне имам Тахави риваять иткән. Хафиз әл-Гайни бу хәдис ту-

www.darul-kutub.com

рында: «Мөслимнең шарты белән иснады дөрестер,» – дигән.

* * *

www.darul-kutub.com

## УНБЕРЕНЧЕ ХӘДИС

### Намазда кыйраәтнең үтәлеше

١١ – عَنْ سَمُرَةَ بْنِ جُنْدَبٍ رَضِىَ اللهُ عَنْهُ : أَنَّ رَسُولَ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ كَانَ يَسْكُتُ سَكْتَتَيْنِ إِذَا دَخَلَ فِي الصَّلاةِ ، وَإِذَا فَرَغَ مِنَ الْقِرَاءَةِ ، فَأَنْكَرَ ذَلِكَ عِمْرَانُ بْنُ الْحُصَيْنِ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُ ، وَكَتَبُوا إِلَى أُبَيِّ بْنِ كَعْبٍ رَضِي اللَّهُ عَنْهُ فِي ذَلِكَ ، فَكَتَبَ إِلَيْهِمْ أَنْ صَدَقَ سَمُرَةُ.

Сәмүра ибне Җүндүбнең (радыйаллаһу ганһү) риваять итүенә күрә:

«Пәйгамбәребез (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) намазга башлаганда һәм кыйраәтне бетергәндә ике кыска тукталыш ясар иде».

Ә Гыймран Хөсәен исә моны инкарь итте. Соңыннан бу мәсьәләне сорап Үбәй ибне

www.darul-kutub.com

Кәгъбкә (радыйаллаһу ганһү) хат яздылар, ул аларга шул җавапны кайтарды: «Әйе, Сәмүраның әйткәне дөрес».

Имам Әхмәд ибне Ханбәл һәм Әбү Дауд (рәхимәһумуллаһ) бу хәдисне риваять иткәннәр.

Хафиз ибне Хәҗәр (рәхимәһуллаһ) бу хәдис-шәриф турында: «Бу хәдис – хәсәндер», – дип әйткән.

***

www.darul-kutub.com

# УНИКЕНЧЕ ХӘДИС

## Намазда кулларны күтәрү

١٢ – عَنْ عَلْقَمَةَ قَالَ : قَالَ عَبْدُ اللهِ بْنُ مَسْعُودٍ رَضِىَ اللهُ عَنْهُ : «أَلَا أُصَلِّي بِكُمْ صَلَاةَ رَسُولِ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عليهِ وسلَّمَ!» ، فَصَلَّى فَلَمْ يَرْفَعْ يَدَيْهِ إِلَّا فِي أَوَّلِ مرَّةٍ .

Имам Гәлькамәдән (рәхимәһуллаһ) Габдуллаһ ибне Мәсгуднең (радыйаллаһу ганһүмә) шулай диеп әйткәне риваять ителә: «Рәсүлуллаһ (сәлләллаһу галәйһи вә сәлләм) нең намазын сезгә кылдырыйммы?»– диде һәм бары тик намазга башлаганда гына кулларын күтәрде».

Бу хәдис-шәрифне Әбү Дауд һәм Тирмизи китергәннәр һәм Ибне Мәсгуднең бу хәдис турында «хәсәндер» дигәнлеге теркәлгән.

www.darul-kutub.com

Сахәбәләрнең һәм табигыйннәрнең күбесе шул фикердә булганнар. Шул ук вакытта бу караш Сүфьян Сәүри һәм Әһле Күфәнең (хәнәфиләр) карашыдыр.

* * *

www.darul-kutub.com

## УНӨЧЕНЧЕ ХӘДИС

١٣ – وَعَنْ عَاصِمِ بْنِ كُلَيبٍ عَنْ أَبِيهِ : أَنَّ عَلِيّاً رَضِىَ اللهُ عَنْهُ كَانَ يرْفَعُ يَدَيْهِ فِى أَوَّلِ تَكْبِيرَةٍ مِنَ الصَّلَاةِ ، ثُمَّ لَا يَعُودُ.

Гасым ибне Күләйб (радыйаллаһу ганһу) үзенең әтисеннән шуны риваять иткән: «Хәзрәти Гали (радыйаллаһу ганһу) намазның беренче тәкбирендә генә кулларын күтәрер иде, бүтән урыннарда кулларын күтәрмәс иде!»

Хәдис-шәрифне Ибне Әбү Шәйбә һәм Тахәви риваять иттеләр. Ибне Хәҗәр (рәхимәһуллаһ) равиләренең «ышанычлы» икәнлеген белдерде.

* * *

www.darul-kutub.com

## УНДҮРТЕНЧЕ ХӘДИС

١٤ – وَعَنِ الْأَسْوَدِ قَالَ : صَلَّيْتُ مَعَ عُمَرَ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُ فَلَمْ يَرْفَعْ يَدَيْهِ فِي شَيْءٍ مِنْ صَلَاتِهِ إِلَّا حِيْنَ افْتَتَحَ الصَّلَاةَ.

Әсүәд (рәхимәһуллаһ) шуны риваять иткән: «Мин Гомәр (радыйаллаһу ганһү) белән намаз кылдым. Ул намазга башлаганда бары тик ифтитах тәкбире өчен генә кулларын күтәрде, бүтән урында кулларын күтәрмәде».

Габделмәликнең (рәхимәһуллаһ) әйтүенчә: «Шәгьби, Ибраһим һәм Әбү Исхак намазга башлаганда кулларын күтәрерләр иде, башка урында исә күтәрмәсләр иде».

Бу хәдис-шәрифне Ибн Әбү Шәйбә (рәхимәһуллаһ) риваять иткән һәм Тахәви (рәхимәһуллаһ) хәдис турында «хәсән» дигән.

www.darul-kutub.com

Хәдисне тапшыручылар турында Ибне Хәҗәр (рәхимәһуллаһ) «сикат» (ышанычлы) дип белдергән.

* * *

www.darul-kutub.com

# УНБИШЕНЧЕ ХӘДИС

## Сәҗдә турында

١٥ – عَنْ وَائِلِ بْنِ حُجْرٍ رَضِىَ اللهُ عَنْهُ قَالَ : «رَأَيْتُ رَسُولَ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيهِ وَسَلَّمَ إِذَا سَجَدَ يَضَعَ رُكْبَتَيهِ قَبْلَ يَدَيْهِ ، وِإِذَا نَهَضَ رَفَعَ يَدَيْهِ قَبْلَ رُكْبَتَيهِ».

Ваил ибне Хүҗер (радыйаллаһу ганһү): «Пәйгамбәребезнең (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) сәҗдәгә киткәндә тезләрен кулларыннан алдан җиргә куйганын һәм калыккан вакытта да кулларын тезләреннән алдан күтәргәнен күрдем,» – дигән.

Бу хәдис-шәрифне Әбү Дауд һәм Нәсаи (рәхимәһумуллаһ) риваять иткәннәр. Тирмизи (рәхимәһуллаһ) исә: «Гыйлем әһленең күбесе бу хәдис белән гамәл кыла иде,»– дигән.

www.darul-kutup.com

## УНАЛТЫНЧЕ ХӘДИС

### Тәкбир, рөкүгь һәм сәҗдә

١٦ – وَعَنْ أَنَسِ بْنِ مَالِكٍ رَضِىَ اللهُ عَنْهُ قَالَ : «رَأَيْتُ رَسُولَ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيهِ وَسَلَّمَ كَبَّرَ فَحَاذَى بِإِبْهَامَيهِ أُذُنَيْهِ ، ثُمَّ رَكَعَ حَتَّى اسْتَقَرَّ كُلُّ مَفْصِلٍ مِنْهُ ، وَانْحَطَّ بِالتَّكْبِيرِ حَتَّى سَبَقَتْ رُكْبَتَاهُ يَدَيْهِ».

Хәзрәти Әнәс ибне Маликтән (радыйаллаһу ганһу) шул рәвештә риваять ителде:

«Пәйгамбәребезнең (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) баш бармагын колак йомшагына тидереп тәкбир әйтүен күрдем. Аннары тәкбир әйтеп, рөкүгъка китте, бөтен буыннары утырганчы иелгән килеш торды. Аннары соң яңадан тәкбир әйтеп, сәҗдәгә кит-

те. Сәҗдәгә иелгәндә тезләрен кулларыннан алда җиргә куйды».

Хәдис-шәрифне Имам Хәким (рәхимәһуллаһ) риваять итеп шулай диде: «Бу хәдиснең иснады Имам Бохари һәм Имам Мүслимнең (рәхимәһәмәллаһ) иснад шартларына карата сахихтыр, әмма алар бу хәдис-шәрифне риваять итмәгәннәр. Бу хәдистә нинди дә булса җитешсезлек яки чир белмим, бу хәдис-шәрифне Зәһәби дә (рәхимәһуллаһ) таныган».

* * *

www.darul-kutub.com

# УНҖИДЕНЧЕ ХӘДИС

## Тәкбир һәм сәҗдә

١٧ – عَنْ وَائِلِ بْنِ حُجْرٍ رَضِىَ اللّٰهُ عَنْهُ : أَنَّهُ رَأَى رَسُولَ اللّٰهِ صَلَّى اللّٰهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ رَفَعَ يَدَيْهِ حِينَ دَخَلَ فِى الصَّلَاةِ ، وَفِيهِ «فَلَمَّا سَجَدَ سَجَدَ بَيْنَ كَفَّيْهِ».

Ваил ибне Хүҗердән (радыйаллаһу ганһү) риваять:

«Мин пәйгамбәребезнең (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) намазга башлаган вакытта кулларын күтәргәнен, сәҗдә кылган вакытта исә куллары арасына сәҗдә кылганын күрдем,»– диде.

Бу хәдис-шәрифне Имам Мүслим (рәхимәһуллаһ) риваять итте.

www.darul-kutub.com

# УНСИГЕЗЕНЧЕ ХӘДИС

## Сәҗдә кылу рәвеше

١٨ – وَعَنْ أَبِي إِسْحَاقَ قَالَ : قُلْتُ لِلْبَرَاءِ بْنِ عَازِبٍ : أَيْنَ كَانَ النَّبِيُّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ يَضَعُ وَجْهَهُ إِذَا سَجَدَ؟ فَقَالَ : «بَيْنَ كَفَّيْهِ».

Әбү Исхактан (радыйаллаһу ганһу) риваять ителгән:

«Мин Бәра ибне Газибтан (рәхимәһуллаһ) пәйгамбәребезнең (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) намаз кылганда йөзен кайда куйганлыгын сорадым. Ул да: «Кулларының арасына куядыр иде,»– диеп җавап бирде».

Хәдис-шәрифне Имам Тирмизи (рәхимәһуллаһ) риваять иткән. Моннан башка шул ук темага Ваил ибне Хүҗер һәм Әбү Хүмәйдтән (рәхимәһүмәллаһ) дә хәдис риваять ителгән.

www.darul-kutup.com

Бәра (рәхимәһуллаһ) бу хәдис-шәриф турында «хәсән, сахих һәм гариб» диде.

* * *

www.darul-kutub.com

## УНТУГЫЗЫНЧЕ ХӘДИС

### Рөкүгъ һәм сәҗдәдә бармакларны кую тәртибе

١٩ – عَنْ وَائِلِ بْنِ حُجْرٍ رَضِىَ اللّٰهُ عَنْهُ : أَنَّ النَّبِيَّ صَلَّى اللّٰهُ عَلَيهِ وَسَلَّمَ كَانَ إِذَا رَكَعَ فَرَّجَ أَصَابِعَهُ ، وَإِذَا سَجَدَ ضَمَّ أَصَابِعَهُ.

Ваил ибне Хүҗердән (радыйаллаһу ганһу) шулай риваять ителгән:

«Пәйгамбәребез (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) рөкүгъка киткән вакытта бармакларын җәя иде, сәҗдәгә киткәндә исә бармакларын берләштерә иде».

Хәдисне Ибне Хиббан һәм Табәрани (рәхимәһумуллаһ) риваять иткәннәр. Хафиз Әл-Хәйсәми (рәхимәһуллаһ) бу хәдиснең «иснады хәсән» дигән.

www.darulkutub.com

## ЕГЕРМЕНЧЕ ХӘДИС

### Сәҗдәдә утыру

٢٠ – عَنْ عَبْدِ اللهِ بْنِ عُمَرَ رَضِىَ اللهُ عَنْهُمَا قَالَ : «مِنْ سُنَّةِ الصَّلَاةِ أَنْ تَنْصِبَ الْقَدَمَ الْيُمْنَى ، وَاسْتِقْبَالُهُ بِأَصَابِعِهَا الْقِبْلَةَ ، وَالْجُلُوسُ عَلَى الْيُسْرَى».

Габдуллаһ ибне Гомәрдән (радыйаллаһу ганһүмә) риваять ителде:

«Уң аякны бөгү, бармакларны кыйблага таба кую һәм сул аяк өстенә утыру намазның сөннәтләреннәндер.»

Хәдисне Имам Нәсаи риваять итте.

* * *

www.darul-kutub.com

# ЕГЕРМЕ БЕРЕНЧЕ ХӘДИС

## Намазда тәүәррук

٢١ – وَفِى حَدِيثِ أَبِى حُمَيْدِ السَّاعِدِىِّ أَنَّهُ ذَكَرَ صَلَاةَ رَسُولِ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيهِ وَسَلَّمَ فِى جَمْعٍ مِنْ صَحَابَةِ رَسُولِ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ فَقَالَ : «ثُمَّ كَبَّرَ فَسَجَدَ ، ثُمَّ كَبَّرَ فَقَامَ وَ لَمْ يَتَوَرَّكْ».

Әбу Хумәд әс-Сагиди (радыйаллаһу ганһу) риваятендә пәйгамбәрнең (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) һәм сахәбәләрнең күбесенең намазын шул рәвештә аңлатты: «Тәкбир әйтеп сәҗдә кылды, аннары соң тәкбир әйтеп, тәүәррук итмичә (сул аягын уң аяк астыннан чыгару һәм уң аякны бөгү) аякка басты».

www.darul-kutub.com

Хәдис-шәрифне Әбү Дауд һәм ИбнеХиббан (рәхимәһумуллаһ) риваять иттеләр. Ибн Хәҗәр (рәхимәһуллаһ): «Бу хәдис сахих», – дигән.

* * *

www.darul-kutub.com

# ЕГЕРМЕ ИКЕНЧЕ ХӘДИС

## Сәҗдәдән соң кыямга басу

٢٢ – عَنْ عَبْدِ اللهِ بْنِ عُمَرَ رَضِيَ اللهُ عَنْهُمَا قَالَ : «نَهَى رَسُولُ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيهِ وَسَلَّمَ أَنْ يَعْتَمِدَ الرَّجُلُ عَلَى يَدَيْهِ إِذَا نَهَضَ فِي الصَّلَاةِ».

Габдуллаһ ибне Гомәрдән (радыйаллаһу ганһүмә) риваять ителде:

«Рәсүлүллаһ (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) намаз укыган бер кешегә кыямга торганда җиргә таянып алуны тыйды».

Хәдис-шәрифне Әбү Дауд, Ибн Хузәймә һәм Хәким (рәхимәһумуллаһ) риваять иткәннәр.

Имам Хәким (рәхимәһуллаһ) бу хәдис-шәрифнең Имам Бохариның һәм Имам Мүслимнең (рәхимәһумуллаһ) шартларына күрә сахих икәнлеген белдерде. Ләкин алар

www.darul-kutub.com

бу хәдис-шәрифне үз китапларында искә алмаганнар.

Имам Зәһәби дә (рәхимәһуллаһ) бу сүзләрне раслады.

* * *

www.darul-kutub.com

# ЕГЕРМЕ ӨЧЕНЧЕ ХӘДИС

## «Әттәхият»не уку

٢٣ – عَنْ عَبْدِ اللهِ بْنِ سَخْبَرَةَ أَبِى مَعْمَرٍ قَالَ : سَمِعْتُ ابْنَ مَسْعُودٍ يَقُولُ : «عَلَّمَنِى رَسُولُ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ ، وَكَفِّى بَيْنَ كَفَّيْهِ ، التَّشَهُّدَ ، كَمَا يُعَلِّمُنِى السُّورَةَ مِنَ الْقُرْآنِ : اَلتَّحِيَّاتُ لِلَّهِ وَالصَّلَوَاتُ وَالطَّيِّبَاتُ ، السَّلَامُ عَلَيْكَ أَيُّهَا النَّبِىُّ وَرَحْمَةُ اللهِ وَبَرَكَاتُهُ ، السَّلَامُ عَلَيْنَا وَعَلَى عِبَادِ اللهِ الصَّالِحِينَ ، أَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ ، وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّداً عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ».

Габдуллаh ибн Сәхбәра, Әбу Мәгъмәрәдән (радыйаллаhу анhу) шуны риваять иткән:

«Мин Ибн Мәсгудтән шуны ишеттем: «Рәсүлүллаh (салләллаhу гәләйhи үә сәлләм)

кулларымны үз куллары арасына алып, миңа Коръәннән бер сүрә өйрәткәндәй, тәшәһһүдне өйрәтте: *«Әт-тәхийййәәтү лилләһи үәс-саләүәәтү үәт-таййибәәт. Әс-сәләәмү галәйкә әййүһән-нәбийү үә рахмәтуллаһи үә бәракәәтүһ. Әс-сәләәмү галәйнәә үә галәә гибәәдилләһис-саалихиин. Әшһәдү әлләәә иләәһә илләллаһү үә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһү үә расүүлүһ»*.

Хәдис-шәрифне Бохари, Мөслим һәм Тирмизи риваять иттеләр. Имам Тирмизи (рәхимәһуллаһ): «Рәсүлүллаһтан (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) риваять ителгән бу хәдис тәшәһһүд турында иң сахих хәдис була», – дигән.

Пәйгамбәребезнең (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) сахәбәләреннән һәм табигыйннәреннән күп гыйлем әһеле шушы хәдис белән гамәл кылган.

Суфьян Сәүри, Ибн Мөбәәрәк, Имам Әхмәд һәм Имам Исхакның

www.darul-kutub.com

(рәхимәһумуллаһ) шул ук фикердә булганнар.

* * *

www.darul-kutub.com

# ЕГЕРМЕ ДҮРТЕНЧЕ ХӘДИС

## Догада бармак күтәрү

٢٤ – عَنْ عَبْدِ اللهِ بْنِ الزُّبَيْرِ رَضِىَ اللهُ عَنْهُمَا ذَكَرَ : أَنَّ النَّبِيَّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ كَانَ يُشِيرُ بِأُصْبُعِهِ إِذَا دَعَا وَلَا يُحَرِّكُهَا.

Габдуллаһ ибне Зөбәйр (радыйаллаһу ганһумә) шулай аңлатты: «Рәсүлүллаһ (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) дога кылганда бармагын күтәреп, аны селкетмәс иде».

Бу хәдис-шәрифне Әбү Дауд һәм Нәсаи (рәхимәһумуллаһ) риваять иткәннәр.

Имам Нәвави (рәхимәһуллаһ): «Әбу Давыд (рәхимәһуллаһ) бу хәдис-шәрифне сахих иснад белән риваять иткән», – диде. Хафиз ибн Әлмүләккин (рәхимәһуллаһ): «Бу сахих хәдистер», – дигән.

www.darul-kutub.com

# ЕГЕРМЕ БИШЕНЧЕ ХӘДИС

## Икенче рәкәгатьтә «Әттәхият»тән соң аякка басу

٢٥ – عَنْ عَبْدِ اللهِ بْنِ مَسْعُودٍ رَضِىَ اللهُ عَنْهُ قَالَ : عَلَّمَنِى رَسُولُ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيهِ وَسَلَّمَ التَّشَهَّدَ فِى وَسَطِ الصَّلَاةِ وَفِى آخِرِهَا ، وَفِيهِ : «ثُمَّ إِنْ كَانَ فِى وَسَطِ الصَّلَاةِ نَهَضَ حِينَ يَفْرُغُ مِنَ تَشَهُّدِهِ».

Габдуллаһ ибне Мәсгуднең (радыйаллаһу ганһу) шуны әйтүе риваять ителә:

«Рәсүлүллаһ (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) миңа тәшәһһүдне намазның уртасында һәм соңында укырга өйрәтте. Намазның уртасындагы тәшәһһүдтән соң аякка торып басарга кушты».

www.darul-kutub.com

Хәдис-шәрифне Имам Әхмәд һәм Ибн Хузәймә (рәхимәһумуллаһ) риваять иткән.

Хафиз әл-Хәйсәми (рәхимәһуллах) хәдис-шәриф равиләренең «мәүсук» икәнлеген белдерде.

* * *

www.darul-kutub.com

## ЕГЕРМЕ АЛТЫНЧЕ ХӘДИС

٢٦ – وَعَنْ عَائِشَةَ رَضِىَ اللهُ عَنْهَا : أَنَّ رَسُولَ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ كَانَ لَا يَزِيدُ فِى الرَّكْعَتَيْنِ عَلَى التَّشَهُّدِ.

Гайшәдән (радыйаллаһу ганһа) килгән риваятьтә шулай диеп әйтелгән:

«Рәсүлүллаһ (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) икенче рәкәгатътә тәшәһһүдкә берни дә өстәмәс иде».

Хәдис-шәрифне Әбу Йәгьлә (радыйаллаһу ганһу) риваять иткән. Мөхәддис Хәйсәми (рәхимәһуллах) бу хәдис-шәрифнең дөреслеген раслаган.

* * *

www.darul-kutub.com

## ЕГЕРМЕ ҖИДЕНЧЕ ХӘДИС

٢٧ – وَعَنْ عَبْدُ اللهِ بْنِ مَسْعُودٍ رَضِىَ اللهُ عَنْهُ عَنِ النَّبِىُّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ : كَانَ فِى الرَّكَعَتَيْنِ الْأُولَيَيْنِ كَأَنَّهُ عَلَى الرَّضْفِ. قَالَ : قُلْنَا : حَتَّى يَقُومَ ؟ قَالَ : حَتَّى يَقُومَ.

Абдуллаһ ибн Мәсгуд (радыйаллаһу ганһу) пәйгамбәребез (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) турында шуны риваять иткән:

«Беренче ике рәкәгатьтәге утыруда кызган таш өстендә сыман утырадыр иде». Аякка торганчы шулай идеме?»– дигәчтен: «Әйе, аякка торганчы шулай иде,»– диеп җавап бирде».

Бу хәдис-шәрифне Әбү Дауд һәм Тирмизи (рәхимәһумуллаһ) китергәннәр.

Факыйһләр бу хәдис белән гамәл иткәннәр, беренче утырышта тәшәһһүдкә

www.darul-kutub.com

берни дә өстәргә кирәкми, дип санаганнар. Берәр нәрсә кушып укылган очракта сәһү сәждәсен кылу кирәклеген әйткәннәр.

Бу хәдис шул ук рәвештә имам Шәгъбидән дә (рәхимәһуллаһ) китерелгән.

* * *

www.darul-kutub.com

## ЕГЕРМЕ СИГЕЗЕНЧЕ ХӘДИС

٢٨ – وَعَنْ تَمِيمِ بْنِ سَلَمَةَ : كَانَ أَبُو بَكْرٍ إِذَا جَلَسَ فِي الرَّكْعَتَيْنِ كَأَنَّهُ عَلَى الرَّضْفِ. يَعْنِي : حَتَّى يَقُومَ.

Тәмим ибн Сәкмәдән (радыйаллаһу анһу) риваять итеlә:

«Әбү Бәкер (радыйаллаһу ганһу) икенче рәкәгатътәге утырудан аякка торганчы кыздырылган таш өстендә сыман утыра иде».

Хәдис-шәрифне Ибн Әбү Шәйбә (рәхимәһуллаһ) риваять итте. Ибне Хәҗәр исә (рәхимәһуллаһ) бу хәдис иснадының сахих булганлыгын сөйләде.

* * *

www.darulkutub.com

## ЕГЕРМЕ ТУГЫЗЫНЧЕ ХӘДИС

٢٩ – عَنِ الْقَاسِمِ بْنِ مُخَيْمَرَةَ قَالَ : أَخَذَ عَلْقَمَةُ بِيَدِى وَحَدَّثنِى: أَنَّ عَبْدَ اللهِ بْنَ مَسْعُودٍ أَخَذَ بِيَدِهِ ، وَأَنَّ رَسُولَ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ أَخَذَ بِيَدِهِ فَعَلَّمَهُ التَّشَهُّدَ فِى الصَّلَاةِ ثُمَّ قَالَ بَعْدَ الشَّهَادَتَيْنِ : «فَإِذَا قَضَيْتَ هَذَا أَوْ قَالَ : فَإِذَا فَعَلْتَ هَذَا فَقَدْ قَضَيْتَ صَلَاتَكَ ، إِنْ شِئْتَ أَنْ تَقُومَ فَقُمْ ، وَإِنْ شِئْتَ أَنْ تَقْعُدَ فَاقْعُدْ».

Касыйм ибн Мөхәймәрәдән риваять итепә:

«Гәлькамә мине кулларымнан тотып, шулай диде: «Габдуллаһ ибне Мәсгуднең (радыйаллаһу ганһумә) әйтүенчә, пәйгамбәребез (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) аны кулларыннан тотып, аңа

тәшәһһүдне өйрәткән. Ә аннан соң аңа шулай дигән: *«Моны укыганнан соң намазың тәмамланган булыр. Теләсәң, торып баса аласың, теләсәң, утырып тора аласың»*.

Хәдисне Имам Әхмәд һәм Әбү Дауд (рәхимәһуллаһ) риваять иткән.

Мөхәддис Әл-Хәйсәми (рәхимәһуллаһ) исә Имам Әхмәд (рәхимәһуллаһ) китергән равиләрнең «сикат» икәнлеген әйткән.

* * *

www.darul-kutub.com

## УТЫЗЫНЧЕ ХӘДИС

٣٠ – عَنْ عَبْدِ اللهِ بْنِ مَسْعُودٍ رَضِىَ اللهُ عَنْهُ : أَنَّ النَّبِيَّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ سَلَّمَ كَانَ يُسَلِّمُ عَنْ يَمِينِهِ وَعَنْ شِمَالِهِ حَتَّى يُرَى بَيَاضُ خَدِّهِ : السَّلَامُ عَلَيْكُمْ وَرَحْمَةُ اللهِ ، السَّلَامُ عَلَيْكُمْ وَرَحْمَةُ اللهِ.

Габдуллаһ ибне Мәсгудтән (радыйаллаһу ганһумә) риваять:

«Рәсүлүллаһ (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) уң һәм сул ягына, яңакларының аклыгы күренгәнче борылып сәлам бирә иде һәм *«Әссәләәмү галәйкүм үә рахмәтүллаһи. Әссәләәмү галәйкүм үә рахмәтүллаһи,»*– дип әйтә иде».

Хәдис-шәрифне Әбү Дауд, Нәсаи һәм Тирмизи (рәхимәһумуллаһ) риваять иткәннәр. Имам Тирмизи шулай дигән: «Ибн Мәсгуд (радыйаллаһу ганһу) китергән бу хәдис «хәсән һәм сахихтыр».

www.darul-kutub.com

Пәйгамбәребезнең (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) сахәбәләре һәм аннан соңгы гыйлем әһелләренең күбесе бу хәдис белән гамәл иткән.

* * *

www.darul-kutub.com

# УТЫЗ БЕРЕНЧЕ ХӘДИС

٣١ – عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُ قَالَ :

«حَذْفُ السَّلَامِ سُنَّةٌ».

Әбү Һүрайрадан (радыйаллаһу ганһу) риваять:

«Пәйгамбәребез (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм): *«Намазда сәламне кыскарту сөннәт санала»,* – дип боерды».

Гали ибн Хәҗәр (рәхимәһуллаһ) Габдуллаһ ибне Мөбәәрәкнең (рәхимәһуллаһ) шулай дип әйтүен хәбәр иткән: «Бу хәдис-шәрифнең мәгънәсе: «Сәламне бер хәреф сузыклыгы кадәр дә озайтмас иде».

Хәдис-шәрифне Тирмизи (рәхимәһуллаһ) риваять иткәндә шулай диде: «Бу хәдис хәсән һәм сахих. Бу риваятьне гыйлем әһеле дә мүстәхәб дип санаган».

www.darulkutub.com

# УТЫЗ ИКЕНЧЕ ХӘДИС

## Иртәнге намазның сөннәте

٣٢ – عَنْ عَبْدِ اللهِ بْنِ أَبِي مُوسَى قَالَ : جَاءَنَا ابْنُ مَسْعُودٍ وَالْإِمَامُ يُصَلِّي فَصَلَّى رَكَعَتَيْنِ إِلَى سَارِيَةٍ ، وَلَمْ يَكُنْ صَلَّى رَكَعَتَيِ الْفَجْرِ.

Габдуллаһ ибн Әбу Мусадан (радыйаллаһу ганһу) риваять ителде: «Яныбызга Ибн Мәсгуд (радыйаллаһу ганһу) килде һәм, имам иртәнге намазны укып бетерүгә карамастан, иртәнге намазның сөннәтен кылды».

Хәдис-шәрифне Табәрани һәм Тахәви (рәхимәһумуллаһ) риваять иткәннәр. Хәйсәми дә (рәхимәһуллаһ) равиләренең ышанычлы булганлыгын әйткән.

Хафиз әл-Гайни (рәхимәһуллаһ) исә: «Тахәви (рәхимәһуллаһ) бу хәдис-шәрифне өч сахих юлдан чыгарды», – дигән.

www.darulkutub.com

## УТЫЗ ӨЧЕНЧЕ ХӘДИС

٣٣ – وَعَنْ أَبِي عُثْمَانَ الْأَنْصَارِيِّ قَالَ : جَاءَ عَبْدُ اللهِ بْنُ عَبَّاسٍ وَالْإِمَامُ فِي صَلَاةِ الْغَدَاةِ ، وَ لَمْ يَكُنْ صَلَّى الرَّكَعَتَيْنِ ، فَصَلَّى عَبْدُ اللهِ بْنُ عَبَّاسٍ رَضِيَ اللهُ عَنْهُمَا الرَّكَعَتَيْنِ خَلْفَ الْإِمَامِ ، ثُمَّ دَخَلَ مَعَهُمْ.

Әбү Госман әл-Әнсаридән (радыйаллаһу анһу) риваять:

«Имам иртәнге намазны кылдырган вакытта, мәчеткә Габдуллаһ ибн Габбас (радыйаллаһу ганһумә) керде. Ул элек ике рәкәгать (сөннәт) намазын кылды, аннан соң җәмәгатькә кушылды».

Хәдис-шәрифне Тахәви (рәхимәһуллаһ) риваять итте.

Хафиз әл-Гайни (рәхимәһуллаһ): «Бу

www.darul-kutub.com

хәдис-шәрифне Тахәви (рәхимәһуллаһ) ике сахих юлдан чыгарды», – диде.

* * *

www.darul-kutub.com

## УТЫЗ ДҮРТЕНЧЕ ХӘДИС

٣٤ – وَعَنْ مَالِكِ بْنِ مِغْوَلٍ قَالَ : سَمِعْتُ نَافِعًا يَقُولُ : «أَيْقَظْتُ ابْنَ عُمَرَ رَضِىَ اللّٰهُ عَنْهُمَا لِصَلَاةِ الْفَجْرِ ، وَقَدْ أُقِيمَتِ الصَّلَاةُ ، فَقَامَ فَصَلَّى رَكَعَتَيْنِ».

Малик бин Мигъфәлдән (рәхимәһуллаһ) риваять ителгән: «Имам Нафигъдән (рәхимәһуллаһ) шуны ишеттем: «Мин Ибн Гомәрне (радыйаллаһу анһумә) иртәнге намазга уяттым һәм камәт китердем, ул да ике рәкәгатъ намаз кылды».

Хәдис-шәрифне Тахәви (рәхимәһуллаһ) риваять иткән. Хафиз әл-Гайни (рәхимәһуллаһ) исә Тахәвинең (рәхимәһуллаһ) бу хәдисне өч сахих юлдан чыгаруын әйткән.

www.darulkutub.com

## УТЫЗ БИШЕНЧЕ ХӘДИС

٣٥ – وَعَنْ أَبِي عُبَيْدِ اللهِ عَنْ أَبِي الدَّرْدَاءِ أَنَّهُ كَانَ يَدْخُلُ الْمَسْجِدَ وَالنَّاسُ صُفُوفٌ فِي صَلَاةِ الْفَجْرِ ، فَيُصَلِّي الرَّكْعَتَيْنِ فِي نَاحِيَةِ الْمَسْجِدِ ، ثُمَّ يَدْخُلُ مَعَ الْقَوْمِ فِي الصَّلَاةِ.

Габдуллаһ Әбү Гобәйдуллаһ (рәхимәһуллаһ) шуны риваять иткән: «Әбу Дәрда (радыйаллаһу анһу) мәчеткә кергәндә, кешеләр саф рәвешендә иртәнге намазны кылып торалар иде. Ул да мәчетнең читендә ике рәкәгать сөннәт намазын кылып бетергәннән соң җәмәгатькә катнашты».

Хәдис-шәрифне Тахәви (рәхимәһул-лаһ) риваять иткән. Хафиз әл-Гайни «Тахәви (рәхимәһуллаһ) бу хәдис-шәрифне сахих иснад белән ихраҗ итте,» – диде.

www.darul-kutub.com

Әбү Гобәйдуллаһның тулы исеме Мүслим бин Мишкәм Әл-Хәзаи Әл-Димәшкый. Ул Әбү Дәрданың (радыйаллаһу ганһу) серкәтибе булган.

* * *

www.darul-kutub.com

# УТЫЗ АЛТЫНЧЕ ХӘДИС

## Сәһү сәҗдәсе

٣٦ – عَنْ عِمْرَانَ بْنِ الْحُصَيْنِ رَضِىَ اللهُ عَنْهُ :
أَنَّ النَّبِيَّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ صَلَّى بِهِمْ فَسَهَا
، فَسَجَدَ سَجْدَتَيْنِ ، ثُمَّ تَشَهَّدَ ، ثُمَّ سَلَّمَ.

Гыймран ибн Хөсәеннән (радыйаллаһу ганһу) шулар риваять ителгән: «Пәйгамбәребез (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) намаз кылдырды һәм намазда нәрсәнедер онытты, ике тапкыр сәҗдәгә киткәннән соң тәшәһһүдне укыды һәм сәләм бирде».

Хәдис-шәрифне Әбү Дауд һәм Тирмизи (рәхимәһумуллаһ) риваять иткәннәр. Имам Тирмизи (рәхимәһуллаһ) хәдис турында: «Сахих, гариб һәм хәсән,» – дигән.

www.darul-kutub.com

Хәким (рәхимәһуллаһ): «Имам Бохари һәм Имам Мүслимнең (рәхимәһуллаһ) шартларына туры килә, ләкин тәхъриҗтә юк иде,»– диде.

Имам Зәһәби (рәхимәһуллаһ) бу сүзләрне раслады.

* * *

www.darul-kutub.com

## УТЫЗ ҖИДЕНЧЕ ХӘДИС

### Намаз вакытында икеләнүләр турында

٣٧ – وَعَنْ عَبْدِ اللهِ بْنِ مَسْعُودٍ رَضِىَ اللهُ عَنْهُ عَنْ رَسُولِ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قَالَ : «إِذَا كُنْتَ فِى صَلَاةٍ فَشَكَكْتَ فِى ثَلَاثٍ وَأَرْبَعٍ ، وَأَكْبرُ ظَنِّكَ عَلَى أَرْبَعٍ : تَشَهَّدْتَ ، ثُمَّ سَجَدْتَ سَجْدَتَيْنِ وَأَنْتَ جَالِسٌ قَبْلَ أَنْ تُسَلِّمَ ، ثُمَّ تَشَهَّدْتَ أَيْضًا ، ثُمَّ تُسَلِّمُ».

Габдуллаһ ибн Мәсгуд (радыйаллаһу ганһумә) Рәсүлүллаһның (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) үзенә шулай дип әйткәнлеген риваять иткән: *«Син намаз кылганда өченче рәкәгатьтәме, югыйсә дүртенчедәме, диеп шикләнсәң, төгәлерәк*

*күренгән фикереңә карата хөкем ит. Әгәр дә дүртенче рәкәгатьтә булсаң, тәшәhhүдне укып ике сәҗдә кыл, аннары соң сәлам биргәнче утырып тәшәhhүдне укы hәм сәлам бирерсең,»* – дигән.

Хәдис-шәрифне Имам Әхмәд hәм Әбү Дауд (рәхимәhумуллаh) риваять иткән.

Хәдиснең мәрфугь дәрәҗәсендә икәнлегенә ихтилаф ителгән.

* * *

www.darul-kutub.com

## УТЫЗ СИГЕЗЕНЧЕ ХӘДИС

## Витер намазы

٣٨ – وَعَنْ أُبَيِّ بْنِ كَعْبٍ رَضِيَ اللهُ عَنْهُ : أَنَّ رَسُولَ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ كَانَ يُوْتِرُ بِثَلَاثٍ ، وَيَقْنُتُ قَبْلَ الرُّكُوعِ.

Үбәй ибне Кәгъбтән (радыйаллаһу ганһу) риваять ителгән: «Рәсүлүллаһ (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) витер намазын өч рәкәгатьтә кыла иде. Рөкүгъка киткәнче кунүт догасын укыр иде».

Хәдис-шәрифне имам Нәсаи һәм Ибне Мажәһ (рәхимәһумуллаһ) риваять иткән.

* * *

www.darul-kutub.com

# УТЫЗ ТУГЫЗЫНЧЫ ХӘДИС
## Кунүт догасы

٣٩ – وَعَنْ عَلْقَمَةَ : أَنَّ ابْنَ مَسْعُودٍ وَأَصْحَابَ النَّبِيِّ صَلَّى اللّٰهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ كَانُوا يَقْنُتُونَ فِي الْوِتْرِ قَبْلَ الرُّكُوعِ.

Имам Гәлькамәдән (рәхимәһуллаһ) риваять ителгән:

«Ибн Мәсгуд (радыйаллаһу ганһумә), пәйгамбәребезнең хөрмәтле сахәбәләре, рөкүгъка киткәнче кунүт догасын укый иде».

Хәдис-шәрифне Ибн Әбү Шәйба (рәхимәһуллаһ) риваять иткән. Ибн Хәҗәр (рәхимәһуллаһ) хәдиснең иснадын «хәсән» диеп белдергән.

Бу риваятьне Табәрани (рәхимәһуллаһ), Ибн Мәсгуднең (радыйаллаһу ганһу)

www.darul-kutup.com

гамәленнән чыгып риваять иткән, ә Ибн Хәҗәр (рәхимәһуллаһ) аның дөреслеген раслаган.

* * *

www.darul-kutub.com

# КЫРЫГЫНЧЫ ХӘДИС

## Сәламнән соң көтү

٤٠ – عَنْ عَائِشَةَ رَضِيَ اللهُ عَنْهَا قَالَتْ : كَانَ النَّبِيُّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ إِذَا سَلَّمَ لَمْ يَقْعُدْ إِلَّا مِقْدَارَ مَا يَقُولُ : أَللَّهُمَّ أَنْتَ السَّلَامُ ، وَمِنْكَ السَّلَامُ تبَارَكْتَ ذَا الْجَلَالِ وَالْإِكْرَامِ.

وَفِي رِوَايَةِ ابْنِ نُمَيْرٍ : «يَا ذَا الْجَلَالِ وَالْإِكْرَامِ».

Гайшә анабыздан (радыйаллаһу ганһа) риваять ителә: «Рәсүлүллаһ (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) фарыз намазларыннан соң сәлам биргәндә «Әллаһуммә әңтәс-сәләәму үә миңкәс-сәләәм. Тәбәәрактә йәә зәл-җәләәли үәл-икраам» сүзләрен укып бетергәнче утырып тора иде.

www.darul-kutup.com

Ибн Нумәйрнең (рәхимәһуллаһ) риваятендә бу көтү «Йә зәл-җәләәли үәл-икраам» буларак телгә алына.

Хәдис-шәрифне Имам Мүслим (рәхимәһуллаһ) риваять иткән.

* * *

www.darul-kutub.com

*Искәрмәләр өчен*

www.darul-kutub.com

Гыйбадәт кылуга кагылышлы
КЫРЫК ХӘДИС. – Казан:
Хузур-Спокойствие, 2014. – 72 бит.

*Книга предназначена для имамов, муэдзинов,*

*преподвателей воскресных курсов при мечетях, а*

*также для широкого круга читателей.*

По вопросам оптовых закупок этой книги
и других изданий обращаться по телефону:
(843) 202-07-74 и по адресам: ул. Газовая, д.
19 (зд. Российского исламского института);
ул. Лобачевского д. 6 (зд. ДУМ РТ).
Сайт издательского дома «Хузур» Huzur.ru

**Одобрено к печати решением № 14-029**

**Экспертного совета ЦРО-ДУМ РТ**

© *Издательство «Хузур-Спокойствие», 1435/2014*

Формат 84x108 1/32, печатных листов: 1,25;
бумага офсетная, печать офсетная, тираж 5000 экз.
г. Казань, пр. Победы, 30, тел.: 251 47 88,
электронная почта: ipk_ppk@mail.ru

Типография «Астор и Я», г. Казань, ул. Ахтямова,
д.13а. Отпечатано в соответствии с предоставлен-
ным электронным материалом.

www.darulkutub.com